СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 16-34 от «23» июля 2019 г.

Муниципаль милектә булган урман кишәрлекләрен һәм яшел утыртмаларны булдыру, тоту һәм саклау Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы прокурорының 2019 елның 15маендагы 02-06-02-2019/11 санлы протесты,“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, 2002 елның 10 гыйнварындагы “Әйләнә-тирә мохитне саклаутурында”гы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 29.01.1997 елдагы 22-ФЗ номерлы Урман кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы СоветыКАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2008 елның 18 декабрендәге 6-23 номерлы карары(алга таба – Карар) белән расланган муниципаль милектә булганурман кишәрлекләрен һәм яшел утыртмаларны булдыру, тоту һәм саклау Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4.3, 4.5., 6.3., 6.18,6.19, 6.20, 7.1., 7.2. пунктларын төшереп калдырырга;
- Муниципаль милектә булган урман кишәрлекләре һәм яшел утыртмалар бәясен исәпләү методикасын һәм карарның 2 пункты белән расланган компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын үз көчен югалткан, дип танырга.

2. Әлеге карарныМамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының Җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов

000074